**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сукаеш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Зур Сукаеш авылы № 6 11.03.2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 37 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (2015 елның 18 августындагы № 19, 2015 елның 29 октябрендәге № 12, 2018 елның 17 апрелендәге № 9, 2018 елның 24 апрелендәге № 10, 2018 елның 15 ноябрендәге № 32, 2018 елның 17декабрендәге № 38, 2019 елның 27 июнендәге № 17, 2019 елның 12 нояберендәге № 29 карарлар редакциясендә)

"Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 23 декабрендәге 374-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Сукаеш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 нгоябрендәге 37 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (2015 елның 18 августындагы № 19, 2015 елның 29 октябрендәге № 12, 2018 елның 17 апрелендәге № 9, 2018 елның 24 апрелендәге № 10, 2018 елның 15 ноябрендәге № 32, 2018 елның 17декабрендәге № 38, 2019 елның 27 июнендәге № 17, 2019 елның 12 нояберендәге № 29 карарлар редакциясендә) 3.2 пунктындагы бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"Салым ташламасына хокукы булган салым түләүче салым органына салым ташламасы бирү турында гариза бирмәгән яисә салым ташламасын кулланудан баш тарту турында хәбәр итмәгән очракта, салым ташламасы Россия Федерациясе Салым кодексы һәм салым түләүченең салым ташламасына хокукы барлыкка килгән салым чорыннан башлап салым органы тарафыннан алынган белешмәләр нигезендә бирелә."

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының Интернет- мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырырга: http://aznakayevo.tatar.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Закирова З.Җ.